ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.09.2017 с. Большие Меми № 6

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Олы Мемми авыл җирлеге Уставының 11 статьясы,

КАРАР БИРӘМ:

1. Олы Меми авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешерсезме:

- Олы Меми авылы территориясендә урнашкан 200 метр озынлыктагы Гаврилов Я.А. урамнары буйлап өлешчә вак таш түшәү, 50 метр озынлыктагы Яшьләр урамы, 100 метр озынлыктагы Заречная урамына юл салу

- Олы Меми авыл җирлеге территориясендә Заборная Поляна авылында урнашкан чишмәнең койма белән уратып алу

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина